ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе эшчәнлеге турындагы мәгълүмат хакында

Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе А.Р. Шәфигуллинның Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе эшчәнлеге турындагы мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе эшчәнлеге турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. Татарстан Республикасының социаль әһәмиятле базарларына аерым игътибар биреп, монополиягә каршы законнарны бозуны кисәтү һәм бетерү эшен дәвам итәргә.

2.2. Социаль әһәмиятле көндәлек азык-төлек товарларына бәяләр куюны, җитештерүчеләрнең яшәү өчен кирәкле һәм мөһим дару препаратларына бәяләр куюын мониторинглауны, шулай ук оператив рәвештә тормыш дәрәҗәсен киметүне булдырмау чараларын күрү максатларында тариф карарларын мониторинглауны гамәлгә ашыруны дәвам итәргә.

2.3. Бюджет акчаларын нәтиҗәле тотуны тәэмин итү максатларында дәүләт хезмәт күрсәтүләре һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр өлкәсендәге законнар үтәлешен тикшереп торуны (аларга күзәтчелек итүне) көчәйтергә. Дәүләт һәм муниципаль заказ бирүчеләрнең сатып алуда катнашучы турында, тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) хакында мәгълүматны намуссыз тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) реестрына кертү буенча мөрәҗәгатьләрен караганда мәгариф һәм медицина оешмаларын, социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмаларны туклану продуктлары белән тәэмин итүгә бәйле хәлләргә аерым игътибар итәргә.

2.4. Сәүдә челтәрен оештыру аша азык-төлек товарларын ваклап сатуны гамәлгә ашыручы хуҗалык итү субъектларының, алар тиешле территориаль берәмлектә алдагы финанс елына барлык сатылган азык-төлек товарларының күләменнән акчалата рәвештә 25 проценттан күбрәк булган өлешкә җиткәндә, Татарстан Республикасы, муниципаль район, шәһәр округы чикләрендә өстәмә сәүдә мәйданнарын сатып алуга яисә арендалауга тыюны үтәүләрен тикшереп торуны (аларга күзәтчелек итүне) көчәйтергә.

2.5. Монополиягә каршы законнарны үтәү мәсьәләләре буенча эшкуарлар бергәлеге белән хезмәттәшлекне активлаштырырга, эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары арасында монополиягә каршы законнарны куллану мәсьәләләре буенча агарту һәм аңлату эшен киңәйтергә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына республика башкарма хакимиятенең тармак органнары һәм җирле үзидарә органнары белән бергә монополиягә каршы законнарны, реклама, табигый монополияләр һәм сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы законнарны мониторинглау эшен дәвам итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 25 сентябре
№ 419-VII ДС